СОВЕТ КУРНАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
КӨРНӘЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Коры Көрнәле ав

13.06.2023 г. № 49

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге Советының 25.06.2018 ел, № 81 карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы № 25-ФЗ , «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 мартындагы № 60-ФЗ федераль законнары, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексына,«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ законы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 3 февралендәге 2-ТРЗ Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге Уставы нигезендә,

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге Советының 25.06.2018 ел, № 81 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) I бүлекнең 1 статьясының 1.4 өлешендә; «, Көрнәле авыл җирлеге сайлау комиссиясен;» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) III бүлектә:

9 нчы статьяның 9.1 нче өлешендәге 5 нче пунктта сүзләр «, Көрнәле авыл җирлеге сайлау комиссиясен;» төшереп калдырырга;

10 статьясының 10.1 өлешендәге 4 пунктында сүзләр, «, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында» төшереп калдырырга;

10 нчы статьяның 10.1 нче өлешендәге 9 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) яллаучының (эш бирүченең) вәкиленә Россия Федерациясе гражданлыгын яки чит ил гражданлыгын (подданствосын) Россия Федерациясе халыкара килешүендә катнашучы чит ил гражданлыгын (подданствосын) туктату турында язма рәвештә хәбәр итәргә, аңа ярашлы рәвештә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы, муниципаль хезмәткәргә бу хакта билгеле булган көнне, әмма Россия Федерациясе гражданлыгы яки чит ил гражданлыгы (подданствосын) туктатылган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча - Россия Федерациясе халыкара килешүендә катнашучы, аңа ярашлы рәвештә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы;»;

10.1 өлешне түбәндәге эчтәлектәге 9_1 пункты белән тулыландырырга:

«9_1) чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) алу турында йә чит ил территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслаучы чит ил документы яисә башка документ алу турында яллаучы (эш бирүчегә) вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә, муниципаль хезмәткәргә бу турыда билгеле булган көнне, ләкин чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) алынган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча йә гражданның чит ил территориясендә яшәргә хокукын раслаучы бүтән документ алган көннән дә соңга калмыйча;»;

11статьяда:

11.1 нче өлешнең 6 нчы пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Россия Федерациясе гражданлыгын туктатты;»;

11.1 нче өлешнең 7 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) чит ил дәүләтенең гражданлыгы (подданствосы) яки чит ил территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслаучы яшәү рөхсәте яки башка документ бар;»;

11.1 өлешне түбәндәге эчтәлектәге 11 пункт белән тулыландырырга:

«11) аның чит ил агенты статусын алуы.»;

11.3 өлешнең беренче абзацын алып ташларга;

11.3 нче өлешнең икенче абзацында сүзләр «, җирлек сайлау комиссиясе аппаратында», «, җирлек сайлау комиссиясе аппаратын» төшереп калдырырга;

12 статьяның 12.1 өлешендә:

1 нче пунктның «в» пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 нче пунктның «а» пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 нче пунктның «б» пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 нче пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясен» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 нче пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясен» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 нче пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясен» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) IV бүлектә:

17 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 17.3 өлеш белән тулыландырырга:

«17.3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә Конкурс Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү буенча Бердәм конкурс комиссиясе тарафыннан Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советы һәм Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге Советы арасында төзелгән кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турындагы килешү нигезендә үткәрелә.».

18 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 18.5 өлеш белән тулыландырырга:

«18.5. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрен аттестацияләү, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск муниципаль районы Советы һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге Советы арасында төзелгән кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турында килешү нигезендә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бердәм аттестация комиссиясе тарафыннан үткәрелә.».

4) VI бүлектә:

21статьяда:

21.2 нче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21.2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге Уставы белән муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә гарантияләр бирелергә мөмкин.»;

түбәндәге эчтәлектәге 21.4 өлеш белән тулыландырырга:

«21.4. Җирле үзидарә органы юкка чыгарылу яки җирле үзидарә органы хезмәткәрләре штаты кыскартылу сәбәпле муниципаль хезмәткәр белән хезмәт килешүе өзелгәндә муниципаль хезмәткәргә гарантияләр бирелә,оешма юкка чыгарылу яки оешма хезмәткәрләре штаты кыскартылу сәбәпле, эшчеләр өчен хезмәт законнары белән билгеләнгән тәртиптә.»;

22 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 22.3 өлеш белән тулыландырырга:

«22.3. Озак еллар хезмәт иткән өчен пенсия муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән кешедә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмаганда билгеләнә.

Күрсәтелгән бурычның күпьеллык хезмәте өчен пенсия билгеләү өчен мөрәҗәгать ителгән көннән алып 90 көн эчендә җайга салынганда, күпьеллык хезмәте өчен пенсия билгеләү шундый билгеләнү өчен мөрәҗәгать иткән көннән алып башкарыла.»;

5) VIII бүлектә:

27 статьяның 27.2 өлешендәге 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган

очракта), муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт үткән чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат формалаштыру һәм күрсәтелгән мәгълүматларны Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының мәгълүмати ресурсларында саклау өчен мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонафицированный) исәп-хисап турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшыру;»;

28.2 өлешендә «, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясен» сүзләрен төшереп калдырырга;

28.3 өлешендә « ,муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенең»,« ,муниципаль берәмлек сайлау комиссиясен», « ,муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенең », сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Көрнәле авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге Башлыгы, Совет рәисе** **Д.Б.Казакова**